**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ТҮБӘН СУЫКСУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«27» февраль 2020 ел Түбән Суыксу авылы № 2/1

«Түбән Суыксу авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2017 елның 22 августтындагы «Җир салымы турында» вн.2/3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 394 статьясы 1 пункты 1 пунктчасы, «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Түбән Суыксу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Түбән Суыксу авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2017 елның 22 августындагы «Җир салымы турында» вн.2/3 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Түбән Суыксу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымы ставкаларын түбәндәге күләмнәрдә билгеләп, җир салымын билгеләргә:

1) авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә торак пунктларда авыл хуҗалыгы кулланылышы зоналары составында һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланыла торган җирләргә карата 0,3%;

2) авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә торак пунктларда авыл хуҗалыгы кулланылышы зоналары составында һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланылмый торган җирләргә карата 1,4%;

3) торак фонды һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектларына керми торган яки торак төзелеше (эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган шәхси торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлегенә хокукындагы өлештән тыш) 0,3%;

4) мәгариф, фән, сәламәтлек саклау, мәдәният һәм спорт административ һәм офис объектларын урнаштыру өчен җирләргә кертелгән җир кишәрлекләренә карата 0,3%;

5) торак фонды биләгән җир кишәрлекләренә карата 0,2 % (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән тыш);

6) башка җир кишәрлекләренә карата 1,5%;

7) җитештерү һәм административ биналар, корылмалар, сәнәгать, коммуналь хуҗалык, матди-техник, азык-төлек белән тәэмин итү, сату һәм әзерләү корылмалары өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата 1,03%;

8) эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган, шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык һәм яшелчәчелек өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә, шулай ук «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата 0,3% ;

9) Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнештә чикләнгән, оборонаны, куркынычсызлыкны һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелгән җир кишәрлекләренә карата 0,3%;

10) 1-3 категорияле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен бирелә торган җир кишәрлекләренә карата 0,05%.

2. Әлеге карар 2020 елның 1 мартыннан, ләкин мәгълүмат стендларында һәм районның рәсми сайтында урнаштырылган көннән соң бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Суыксу авыл җирлеге Советының законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Ф.Г.Ихсанов